# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

## № 2

февраль

1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 2*
*февраль*
*1999*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1999

Лицензия № 174 1996 елның 03.10 бирелде
Җитештерүгә тапшырылды
Формат А5. Оригинал-макеттан басылды
Тиражы 1000 нөсхә. Заказы 001683
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н. Ершов ур., 31б.
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хезмәт күрсәтү үзәгендә басылды.
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде.
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105.

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*
**Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы
© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 1999

## Эчтәлек

### I

420."Татарстан Республикасы Дәүләт Советы унсигезенче пленар сессиясенең көн тәртибе турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 6
421."Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенә имза салуга 5 ел тулу хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белдерүе турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 7
422."Татарстан Республикасы Конституциясенең 89,111 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы Законы проектын эшләүне дәвам итү хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 10
423."Иминлек турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 11
424."Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы Законына згәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 11
425."1999 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару эшенең якынча планы турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 12
426."Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасына кандидатура турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 12
427."Татарстан Республикасы Югары суды судьяларын сайлау турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 13
428."М.Ш.Халитовның Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 13
429."Әфганстан Республикасыннан совет гаскәрләренең чикләнгән контингентын чыгаруга 10 ел булу уңаеннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белдерүе турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 14
430."Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын эшләүне дәвам итү хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 16

431."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 18 февралендәге утырышы көн тәртибе турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 17
432."Экологик экспертиза турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 18
433."Татарстан Республикасының Су кодексы проектын эшләүне дәвам итү турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ... 18
434."Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышка тәкъдим итү вакытын озайту хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 19
435."Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары вәкилләренең җыелышын уздыру вакытын күчерү турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 19
436."1999-2003 елларга Татарстан Республикасының Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча комплекслы дәүләт программасы проекты турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 20
437."Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 21

**II**

438."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ..... 22
439."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ..... 23
440."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы язгы сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 24
441."1999 елның 18 февралендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 24
442."1999 елның 18 февралендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 25
443."Латин графикасына нигезләнгән татар әлифбасын торгызу

турында" Татарстан Республикасы законы проекты буенча парламент тыңлауларын уздыру турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........................................ 26
444."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 гыйнварендагы утырышында Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........................ 27

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 420. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы унсигезенче пленар сессиясенең көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы унсигезенче пленар сессиясенең түбәндәге көн тәртибен расларга:

1.Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы турында.

2.“Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында” Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенә имза салынуга биш ел тулу турында.

3.“Янгын куркынычсызлыгы турында”,“Татарстан Республикасы гражданнарын медицина иминләштерүе турында”, “Татарстан Республикасында юллар фонды турында”, “Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына кертемнәрнең 1997 елга иминлек тарифы турында” Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Законын кабат карау турында.

4.“Татарстан Республикасына аеруча зур хезмәт күрсәткән гражданнарны өстәмә матди тәэмин итү турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

5.“Татарстан Республикасы Конституциясенең 89,111 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

6. “Иминлек турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

7. “Җир өчен түләү турында” Татарстан Республикасы

Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

8. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында.

9. 1999 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару эшләренең якынча планы проекты турында.

10.Татарстан Республикасы Югары суды судьяларын сайлау турында.

11. М.Ш.Халитовның Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

12. Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасына кандидатура турында.

13. Әфганстан Республикасыннан совет гаскәрләренең чикләнгән контингентын чыгаруга 10 ел булу уңаеннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белдерүе турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 12 феврале
№ 1990

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 421. "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенә имза салуга 5 ел тулу хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белдерүе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенә имза салуга 5 ел тулу хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белдерүен кабул итәргә.

2. Әлеге карарны һәм күрсәтелгән белдерүне Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Федерация Советына һәм Дәүләт Думасына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенә, Россия Федерациясе субъектлары хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 12 феврале
№ 1991

## "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенә имза салуга биш ел тулу хакындаТатарстан Республикасы Дәүләт Советы БЕЛДЕРҮЕ

1999 елның 15 февралендә "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенә имза салганга 5 ел тула. Бу тарихи документ тигез хокуклылык, ихтыярыйлык һәм ихтыярын ирекле белдерү принципларында берләшкән Россия Федерациясе белән Татарстан мөнәсәбәтләрендә яңа этапны билгеләде.

Россия Федерациясе белән шартнамәчел мөнәсәбәтләр урнаштыруның зарурлыгы турында беренче мәртәбә 1990 елны Татарстан Республикасының Дәүләт суверенитеты турындагы декларациядә белдерелгән иде. Аннары республика халкы суверенитетны һәм федераль үзәк белән шартнамәчел мөнәсәбәтләрне ныгыту курсын хуплавын 1992 елның мартында уздырылган референдумда раслады. Безнең күп милләтле халкыбызның ихтыяры Татарстан Республикасы Конституциясендә беркетелде. Шулай итеп, Шартнамә Татарстан суверенитетын юридик беркетүнең мантыйкый төгәлләнеше булды. Ул, Татарстан халкының этник, конфессиональ һәм социаль

мәнфәгатьләре балансының нигезе булып, Россиядә һәм Татарстанда тотрыклылыкның алшартларын барлыкка китерде.

Шартнамә, якларның мәнфәгатьләрен килештереп, ике Конституцияне - Татарстан һәм Россия Федерациясе конституцияләрен тануга таяна. Шуңа күрә дә ул, сәяси һәм юридик документ буларак, ике Конституция арасындагы коллизияләрне юкка чыгара. Үткән биш ел республиканың федераль үзәк белән легитим мөнәсәбәтләрен барлыкка китерүче шартнамәчел мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәлелеген күрсәтте. Шартнамәне гамәлгә ашыру механизмын билгеләүче һәм дәүләт учреждениеләре эшчәнлеге өчен күрсәтмә булган килешүләр пакеты Шартнамәнең аерылмас өлеше булды.

Шартнамәнең потенциалы гаять зур һәм ул Дәүләт Советы кабул итә торган законнарда, шулай ук хөкүмәтара килешүләрдә киләчәктә үстерә баруны таләп итә.

Шартнамә Россия федерализмын торгызуда да мөһим дәверне билгеләде. Россия дәүләтчелеген яңартуның катлаулы күчеш чорында ул унитаризмга кире кайтуга киртә генә булмыйча, яшәргә сәләтле асимметрик федерация барлыкка китерерлек хокукый база тәкъдим итте. Россия федерализмын торгызуның шартнамәчел-конституциячел принцибы, Россиядәге тотрыклылык өчен ышанычлы сәяси һәм юридик база гына булмыйча, төбәкләр арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу буенча төзелгән шартнамәләрне дә исәпкә алып, хакимиятнең федераль органнарга үз эшчәнлекләрен, шул исәптән закон чыгаруны да гамәлгә ашыруны йөклиләр.

Шартнамә Татарстанга халыкара аренага чыгу, чит ил базарларын саклап калу, инвесторларны һәм икътисадый хезмәттәшлек буенча партнерларны җәлеп итү өчен киң мөмкинлекләр ача. Тышкы актив эшчәнлек республиканың абруен арттыруга китерә. Күп кенә дәүләт эшлеклеләренең һәм көнбатыш галимнәренең сәяси лексиконнарында, дәүләт корылышының һәм конфликтларны җайга салуның катлаулы мәсьәләләрен хәл итүнең цивилизацияле алымы буларак, “Татарстан моделе” төшенчәсе кулланыш таба.

Республиканың күп милләтле халкы ихтыярын белдереп, Дәүләт Советы:

– республика дәүләтчелеген үстерүнең иң мөһим факторы буларак, Татарстан белән Россиянең шартнамәчел мөнәсәбәтләрен ныгытуның, шулай ук Россия Федерациясендә

һәм Татарстанда тотрыклылыкны саклап калуның сәяси әһәмиятен билгеләп үтә;

– Татарстан Республикасының, суверен дәүләт буларак, башка төбәкләр кебек үк үзенең тарихи, милли, конфессиональ, икътисадый һәм башка үзенчәлекләргә ия булуын искә төшерә. Шуңа күрә Россия асимметрик федерация буларак төзелергә тиеш;

– Россия Федерациясенең иң югары закон чыгару органында Милләтләр Палатасын булдыруны максатка ярашлы дип саный;

– Россияне "губерналаштыру" дип атала торган, халык ихтыярын исәпкә алмыйча, милли республикаларны юкка чыгаруны һәм гамәлдәге административ чикләрне үзгәртеп коруны күз алдында тотучы планнарның куркыныч булуы турында кисәтә.

Дәүләт Советы Шартнамәдә республика үзенә алган йөкләмәләрне хуплавын раслый һәм Россия белән Татарстан арасындагы шартнамәчел мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе халыклары мәнфәгатьләрендә алга таба камилләштерергә кирәклекне ассызыклый.

---

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 422. "Татарстан Республикасы Конституциясенең 89,111 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы Законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Татарстан Республикасы Конституциясенең 89,111 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, ихтимал булган эчке хокукый каршылыкларын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен урнаштыру өчен Татарстан Респуб-

ликасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 12 феврале
№ 1992

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 423. "Иминлек турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Иминлек турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 12 феврале
№ 1993

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 424. "Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы

Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. "Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында мөмкин булган эчке хокукый каршылыкларны бетерү, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китереп, статьяларның үзара дөрес бәйләнешләрен урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 12 феврале
№ 1994

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 425. 1999 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару эшенең якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1999 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару эшенең якынча планын хупларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 12 феврале
№ 1995

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 426. Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасына кандидатура турында

Россия Федерациясенең икенче состав Үзәк сайлау комиссиясенең вәкаләтләр чоры узуга бәйле һәм "Сайлау хокукларының һәм Россия Федерациясе референдумында

катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 22 статьясындагы 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Россия Федерациясенең өченче состав Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы урынына билгеләү өчен Бикташиров Раиф Терентьевич кандидатурасын Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Федерация Советына тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 12 феврале
№ 1996

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 427. Татарстан Республикасы Югары суды судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Түбәндәгеләрне Татарстан Республикасы Югары суды судьялары итеп сайларга:

Закирова Наилә Гомәр кызын,
Кәлимулин Рафаил Ярулла улын,
Федоров Леонид Алексеевичны,
Худобин Юрий Павловичны.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 12 феврале
№ 1997

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 428. М.Ш.Халитовның Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

21 нче Аксубай административ-территория сайлау округыннан Татарстан Республикасы халык депутаты М.Ш.Халитовның Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләрен

туктатуы турында язмача гаризасы һәм “Татарстан Республикасы халык депутаты статусы турында” Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Халитов Марс Шәфыйк улының Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган дип санарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 12 феврале
№ 1998

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 429. Әфганстан Республикасыннан совет гаскәрләренең чикләнгән контингентын чыгаруга 10 ел булу уңаеннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белдерүе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Әфганстан Республикасыннан совет гаскәрләренең чикләнгән контингентын чыгаруга 10 ел булу уңаеннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белдерүен кабул итәргә.

2. Әлеге карарны һәм күрсәтелгән белдерүне республика массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 12 феврале
№ 1999

## Әфганстан Республикасыннан совет гаскәрләренең чикләнгән контингентын чыгаруга 10 ел булу уңаеннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы БЕЛДЕРҮЕ

Әфганстан Республикасыннан совет гаскәрләренең чикләнгән контингентын чыгаруга 15 февральдә ун ел була.

Безнең өчен бу көн - Туган илебез чакыруы буенча китеп,

гомерләре шунда өзелгән улларыбыз турында хәтер көне. Алар Әфганстан юлларында дус халыкка ярдәм итүләренә нык ышанып йөрделәр. Бүген, аларның рухларын рәнҗетеп, Әфганстанда кем булулары һәм нәрсә эшләүләре хакында бәхәсләр алып бару әхлаксызлык, иң мөһиме - үткәннән сабак алу һәм шуны беркайчан да онытмау. Тарихны яңадан язып булмый.

Бу сугыш фаҗигаләре Татарстанны да читләтеп үтмәде. Тугыз мең ярымнан артыграк якташыбыз шушы авырлыкларны үттеләр. Күпләре әйләнеп кайтты. **Яшәр** өчен кайтты. 233 якташыбыз гомерлеккә инвалид булып калды, 536 сы - яраланды һәм гарипләнде. Татарстаннан киткән 1665 кеше сугышчан батырлыклары өчен орден, медальләр белән бүләкләнде, республикабызның 260 яшь егете мәңгелеккә ятып калдылар. Бүген алар да безнең арада яшәрләр, балалар үстерерләр, ата-аналарын сөендерерләр иде... Язмыш башкача хөкем йөртте. Алар рухы алдында баш иябез. Без әлегә кадәр хәсрәт эчендә яшәүче аналар, тол калган офицер хатыннары алдында баш иябез. Сезнең күңелләрдәге кебек үк безнең күңелләрдә дә югалту ачысы, югалту аянычы.

Без һәлак булганнар алдында гына түгел, аларның гаиләләре алдында һәм Әфганстанда хәрби бурычларын үтәп, исән-имин кайтканнар алдында да бурычлы. Алар үзләрен онытылган һәм кыерсытылган итеп хис итмәсеннәр. Кабат-кабат сынамыйк аларны. Кызганычка каршы, мондый фактлар бар. Әлегә пособиеләрне вакытында түләү тоткарланып килә, торак шартларын яхшыртуда, медицина хезмәте күрсәтүдә хәл ителмәгән мәсьәләләр шактый. Мондый проблемаларны икътисадый һәм финанс кыенлыкларына бәйле объектив сәбәпләр белән аңлатып булса, кешелеклелек, рәхим-шәфкатьлелек кытлыгы берничек тә аңлашылмый. Әфган мәхшәрендә кайнашкан бу ирләр, Татарстанда булган үзгәрешләргә үзләреннән зур өлеш кертеп, милләтара татулыкны һәм үзара ярдәм итешүне ныгытып, фидакарьләрчә эшлиләр һәм яшиләр.

1999 елның 8 февралендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты “Әфганстан Республикасыннан гаскәрләрне чыгаруның 10 еллыгына багышланган чаралар турында” карар кабул итте. Ул Әфганстандагы хәрби вакыйгаларда катнашкан ветераннарга, һәлак булганнарның гаиләләренә медицина ярдәме күрсәтүгә, социаль реабилитацияләүгә юнәлдерелгән. Моннан тыш, Хөкүмәт Әфган сугышында һәлак булган сугышчыларның “Хәтер китабы”н бастырып чыгару

турында карар кабул итте.

Әфган сугышында катнашучыларга, һәлак булганнарның гаиләләренә, аларның якыннарына һәм туганнарына нык сәламәтлек, күркәм сабырлык, зур уңышлар телибез һәм дәүләт аларны һәрдаим кайгыртып торыр дип белдерәбез.

---

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 430. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән искәрмәләрне, тәкъдимнәрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.
2. Әлеге карар проектына төзәтмәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенә 1999 елның 12 мартына кадәр кертелә, дип билгеләргә.
3. Күрсәтелгән карар проектын карау өчен һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенә кисәтүләр, тәкъдимнәр бирү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка даими комиссияләренә җибәрергә.
4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенә 1999 елның 12 апреленә кадәр, алынган кисәтүләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, әлеге карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына икенче укылышка кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 12 феврале
№ 2000

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 431. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 18 февралендәге утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 18 февралендәге утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1.Социаль партнерлык турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

2. 1999-2003 елларга Гадәттән тыш вәзгыятьләрне кисәтү буенча Татарстан Республикасының дәүләт комплекслы программасы проекты турында.

3."Экологик экспертиза турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

4. Татарстан Республикасының Су кодексы проекты турында.

5."Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышка тәкъдим итү вакытын озайту хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

6."Вөҗдан ирекле һәм дини берләшмәләр турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышка тәкъдим итү вакытын озайту хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

7.Россия Федерациясе Президентының Гомуми юрисдикция судлары турында" федераль конституциячел закон проектын әзерләгән Баш дәүләт-хокук идарәсе инициативасын хуплау хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 18 феврале
№ 2002

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 432. "Экологик экспертиза турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Экологик экспертиза турында" Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 18 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый байлыклар һәм табигатьтән файдалану комиссиясенә җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый байлыклар һәм табигатьтән файдалану комиссиясе күрсәтелгән закон проектын, кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, 1999 елның 18 апреленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 18 феврале
№ 2003

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 433. Татарстан Республикасының Су кодексы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасының Су кодексы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән тәкъдимнәрне, искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән проектка төзәтмәләр 1999 елның 18 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый байлыклар һәм

табигатьтән файдалану комиссиясенә җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый байлыклар һәм табигатьтән файдалану комиссиясе күрсәтелгән проектны, кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, 1999 елның 18 апреленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 18 феврале
№ 2006

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 434. "Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышка тәкъдим итү вакытын озайту хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

"Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында" Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экологик иминлек һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан икенче укылышка тәкъдим итү вакытын 1999 елның 25 февраленә кадәр озайтырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 18 феврале
№ 2007

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 435. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары вәкилләренең җыелышын уздыру вакытын күчерү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 гыйнварендагы 1970 номерлы "Татарстан Республикасы

җирле үзидарә органнары вәкилләренең җыелышын уздыру турында”гы карарын үзгәртеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары вәкилләренең җыелышын уздыру вакытын күчерергә.

2. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары вәкилләренең җыелышын уздыру көнен билгеләүне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 18 феврале
№ 2008

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 436. “1999-2003 елларга Татарстан Республикасының Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча комплекслы дәүләт программасы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. 1999-2003 елларга Татарстан Республикасының Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча комплекслы дәүләт программасын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. 1999-2003 елларга Татарстан Республикасының Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча комплекслы дәүләт программасының үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый ресурслар һәм табигатьтән файдалану комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 18 феврале
№ 2009

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 437. "Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында" Татарстан Республикасы законы проектын Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе тарафыннан тәкъдим итү вакытын озайтырга.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләрне 1999 елның 25 февраленә кадәр Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясенә кертергә, дип билгеләргә.

3. Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 1999 елның 25 мартына кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 18 феврале
№ 2010

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 438. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1."Янгын куркынычсызлыгы турында","Татарстан Республикасы гражданнарын медицина иминләштерүе турында", "Татарстан Республикасында Юллар фонды турында", "Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына кертемнәрнең 1997 елга иминлек тарифы турында" Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законын кабат карау турында.

2. "Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

3. 1999 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару эшләренең якынча планы проекты турында.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында.

5. М.Ш.Халитовның Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

6. Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасына кандидатура турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 3 феврале
№ 1974

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 439. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе каравына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге карарлары проектларын кертергә:

1. "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенә имза салуга 5 ел тулу хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белдерүе турында.

2. "Янгын куркынычсызлыгы турында","Татарстан Республикасы гражданнарын медицина иминләштерүе турында", "Татарстан Республикасында Юллар фонды турында", "Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына кертемнәрнең 1997 елга иминлек тарифы турында" Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законын кабат карау турында.

3. "Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 111 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

4. "Иминлек турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

5. Татарстан Республикасы Югары суды судьяларын сайлау турында.

6. "Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты эшләүне дәвам итү турында.

7.1999 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында

закон чыгару эшләренең якынча планы проекты турында.

8. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында.

9. М.Ш.Халитовның Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

10. Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасына кандидатура турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 3 феврале
№ 1975

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 440. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы язгы сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы язгы сессиясенең чираттагы утырышын 1999 елның 18 февралендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 3 феврале
№ 1977

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 441. 1999 елның 18 февралендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 18 февралендә Татарстан Республикасы

Дәүләт Советы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1."Лицензияләү турында" Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

2."Социаль партнерлык турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

3. 1999-2003 елларга Гадәттән тыш вәзгыятьләрне кисәтү буенча Татарстан Республикасының дәүләт комплекслы программасы проекты турында.

4."Экологик экспертиза турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

5. Татарстан Республикасының Су кодексы проекты турында.

6."Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышка тәкъдим итү вакытын озайту хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

7."Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышка тәкъдим итү вакытын озайту хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

8. "Гомуми юрисдикция судлары турында" федераль конституциячел закон проектын әзерләгән Россия Федерациясе Президентының Баш дәүләт-хокук идарәсе инициативасын хуплау хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 3 феврале
№ 1978

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 442. 1999 елның 18 февралендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 18 февралендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге карарлары проектларын кертергә:

1. "Лицензияләү турында" Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

2. 1999-2003 елларга Гадәттән тыш вәзгыятьләрне кисәтү буенча Татарстан Республикасының дәүләт комплекслы программасы проектын эшләүне дәвам итү турында.

3. "Экологик экспертиза турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

4. Татарстан Республикасының Су кодексы проектын эшләүне дәвам итү турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 3 феврале
№ 1979

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 443. "Латин графикасына нигезләнгән татар әлифбасын торгызу турында" Татарстан Республикасы законы проекты буенча парламент тыңлауларын уздыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

"Латин графикасына нигезләнгән татар әлифбасын торгызу турында" Татарстан Республикасы законы проекты буенча парламент тыңлауларын 1999 елның 17 мартында уздыруны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 3 феврале
№ 1981

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 444. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 гыйнварендагы утырышында Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 гыйнварендагы утырышында Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәрне карауны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләренә йөкләргә (кушымта итеп бирелә).

Тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре турында бер айдан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы халык депутатларына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына хәбәр итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре В.Н.Липужинага хәбәр итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 3 феврале
№ 1985